*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2024-2025 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 60**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **2** | **1** | **1** | **2** | **2** | **2** | **1** |

## II. Теоретик бирем.

Иҗек турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**7 балл**)
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм аның ясалышын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) көнбагыш | 1) тамыр сүз |
| Ә) пыяла | 2) ясалма сүз |
| Б) сиртмә койрык | 3) саф кушма сүз |
| В) ямьле | 4) тезмә сүз |
| Г) әйлән-бәйлән | 5) парлы |

**Җавап : 31425**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Биологиядән “икеле” алуына һич тә үкенмәде Камил. Чөнки бу фәнне ул башкаларга караганда яхшырак белә. “Икеле” алуының сәбәбе дә көлке сыман: контроль эш дәфтәрен тапшырмаган. Эшен беренче булып (эшләгән / **төгәлләгән** / биргән) иде дә, янәшә партада утыручы Сәриянең (эшен / **биремен** / мисалын) эшли алмаганын күреп, укытучы сизмәгәндә генә, дәфтәрен аңа сузды. Дәрес бетеп, тәнәфескә кыңгырау шылтырагач, укытучы үзе (әйтеп / карап / **йөреп**) җыйды дәфтәрләрне. Минем дәфтәр Сәриядә дип (сөйләмәс / дәшмәс / **әйтмәс**) бит инде! (Д. *Гайнетдиновадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)** Һәр җавапка – 0,5 балл

Яңа ел җитте! Яңа ел!
Кышы, Язы, ҖәЕ, КӨзе –
БарЫсы белән дә яңа ул.
Ә иске ел ерак китте.
Киткән чакта елап китте.
Ул соңниләр алып китте,
Һәм нИләр калдырып китте? (*Р. Гаташ*)

3. Шигырьдән антоним исем һәм сыйфатларны парлап күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(6 балл)**

**яңа – иске** (сыйфатлар), **кышы – җәе, язы – көзе** (исемнәр)

---

4.*Кыш* сүзенә 3 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(6 балл)**
**кышкы, кышлык, кышлау**
5. "Тиздән Яңа ел" темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)